ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2021 № 87

2021 елга Алабуга муниципаль
районының муниципаль гомуми
белем бирү оешмаларында укучыларның
тукלануын тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге «Татарстан Республикасында социаль стандартлар һәм социаль табигый нормалар турында 1022 номерлы карары, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-2О СанПиН кагыйдәләрен һәм таләпләрен раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2017 елның 8 августындагы 566 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен, укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү нормаларын үтәү, аларның сәламәтлеген саклау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның тукלануын оештыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәгеләрне билгеләргә:

- бер укучыга көненә бер тапкыр кайнар туклануның уртача бәясен: 1-4 сыйныфларда укучы балаларга – 53,41 сум, ә 5–11 сыйныфларда укучы балаларга – 43 сум күләмендә;
- бер укучыга көненә ике тапкыр кайнар туклануның уртача бәясен: 1-4 сыйныфларда укучы балаларга - 80,25 сум, ә 5-11 сыйныфларда укучы балаларга - 71,4 сум күләмендә;

5-11 сыйныфларда укучы балаларга - 8 сум 00 тиен күләмендә туклану бәясе җирле бюджет акчаларыннан түләнә, аерма ата-аналар түләве хисабына.

3. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә бер укучыга көненә, бушлай кайнар туклануның бәясен 8 сум 00 тиен күләмендә билгеләргә.

4. Тәэмин итәргә:

4.1. Бушлай кайнар аш белән түбәндәге категория укучы балаларын тукландыруны:

- башлангыч гомуми белем алучы балалар;
- 4 һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган яшьтәге балалары булган гаиләләрдә тәрбияләнгән укучы балалар;
- гаиләдә бер кешегә туры килә торган уртача керем яшәү минимумыннан кимрәк булган балалы гаиләләрдәге баллар;

Гаиләнең җан башына уртача керем яшәү минимумы «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы мәгариф идарәсе» МКУ һәм «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ГКУ арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү нигезендә билгеләнә.

- фтизиатрда дәваланучы балалар;
- дәүләт учреждениеләрендә тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалар;
- биш көнлек хәрби җыеннарда катнашучы 10 сыйныф үсмерләре.

4.2. Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны ике тапкыр бушлай кайнар аш белән тукландыруны.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусы медик-социаль экспертиза (МСЭ) белән билгеләнә.

5. 2021 елда кайнар аш белән туклануның компенсация күләмен җирле бюджет хисабыннан бер укучы өчен көненә 8 сум 00 тиен күләмендә билгеләргә.

6. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, уку чорында гомуми белем бирү

учреждениеләренең барлык укучылары өчен кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырыруны тәкъдим итәргә.

7. Республика матди ярдәм үзәгенең Алабуга муниципаль районындагы № 19 бүлегенә «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе һәм «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү нигезендә, социаль ярдәм чаралары алучылар хакында мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.

8. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль дәүләт казна учреждениесе башлыгына Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә куллану юлы белән Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматларга туры китереп әлеге социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

9. Азык-төлек операторына витаминнар, минераль матдәләр микъдары һәм туклыклылык буенча балансланган туклану нормаларын һәм сыйфатын үтәүне исәпкә алуны һәм тикшереп торуны тәкъдим итәргә.

10. Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

10.1. укучы балаларны кайнар аш белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән чараларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

10.2. Алабуга муниципаль районы белем бирү учреждениеләренә продуктларны өзлексез китерүне координацияләргә һәм контрольдә т тотуны тәэмин итәргә;;

10.3. китерелә торган азык-төлек продуктларының сыйфатын контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

10.4. Укучыларның комплекслы төшке ашлары өчен ата-ана түләвенең тулы һәм вакытында килүен тәэмин итәргә.

11. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү

оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2020 елның 11 февралендәге 123 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

12.Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

13. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 87 ” 01.02.2021 ел
карарына кушымта

# Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында Нигезләмә

# 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турындагы әлеге Нигезләмә укучыларның туклануын оештыру, финанс белән тәэмин итү тәртибен, туклануны оештыру процессында катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын билгели.

1.2. Нигезләмә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру, балаларга социаль ярдәм күрсәтү һәм аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү процессының уңайлы мохитен булдыру максатларында эшләнә.

1.3. Укучыларны туклandыруны оештыру Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алабуга муниципаль районының норматив хокукый актлары, Федераль санитар кагыйдәләр, нормалар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.4. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплылык, кергән бюджет акчаларын һәм ата-аналар түләвен исәпкә алу һәм тикшереп тору учреждение җитәкчесенә йөкләнә.

1.5. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе гомуми белем бирү оешмаларында туклануга каралган бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп контрольдә тота.

# 2. ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ

2.1. Белем бирү учреждениеләрендә туклануны оештыру яки азык-төлек продуктларын китерүне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар арасындагы мөнәсәбәтләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән контракт (килешү) белән җайга салына. Белем бирү оешмалары өчен азык-төлек сатып алу «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Туклануны оештыручы мәктәп ашханәсе түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- квалификацияле кадрлар (раслаучы документлар булырга тиеш);
- һәр хезмәткәргә шәхси медицина кенәгәсе;
- белем бирү программасы курсларында хезмәткәрне укыту һәм яңадан әзерләү буенча кимендә 2 елга 1 тапкыр гигиенага кагылышлы укулар оештыру;

- азык-төлек продуктларын кабул итүгә продуктның сыйфатын һәм куркынычсызлыгынраслыйлаучы һәм тиешле керем документлары;

- ризыкның технологик карталары;
- белем бирү учреждениесенә азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү гамәлгә ашырылса, җитештерү контроле программасы кысаларында лаборатор инструменталь тикшеренүләр уздыру турында гамәлдәге шартнамәнең (квартал саен) булу шарт;
- Башкарма хакимиятнең территориаль органы белән килештерелгән, дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне башкарырга вәкаләтле директор тарафыннан расланган, санитар-эпидимиологик таләпләргә һәм нормаларга җавап бирүче перспектив ун көнлек кайнар туклану, балансллы туклану менюсы (шул исәптән озайтылган көн төркеме, хәрби җыеннар) булу шарт;
- авыл хуҗалыгы терлекләрен, кош-корт, балык сатып алуга, саклауга, әзерләүгә тиешле документлар һәм ит, балык ризыкларын тиешле эшкәртү буенча ветеринария таныклыгы булу шарт;
- керә торган чималның, ярымфабрикатларның сыйфатын раслый торган документлар (сертификатлар турында белешмәләр, продукцияне әзерләү һәм сату вакытлары күрсәтелгән туры килү сертификатлары) булу шарт;
- бәяләмәләр һәм тәкъдимнәр китабы;
- башкаручы турында мәгълүмат булу.

2.3. Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклындыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-2О СанПиН кагыйдәләрен һәм таләпләрен раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары нигезендә, бер укучыга туклану нормалары көнгә гомуми белем бирү оешмаларында, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклындыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр раслана.

2.4. Ризыкны җитештергәндә туклануны оештыручы азык-төлек блогы хезмәткәрләре чималны салкын һәм җылылык белән эшкәртүнең гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнгән технологик режимын үтәргә тиеш.

2.5. Укучыларның туклануын оештыруны тикшереп тору администрация һәм җәмәгать комиссия тарафыннан белем бирү оешмасының эшен тикшереп тору гамәлгә ашырыла.

Әзер продукциянең куелган таләпләргә җавап бирү дәрәҗәсен бракераж (әзер ризыкны бәяләү) комиссиясе билгели, аның составына: җитештерү мөдире, медицина хезмәткәре, директор боерыгы белән

билгеләнгән кеше гомуми белем бирү учреждениесендә туклануны оештыру өчен җаваплы.

Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру өчен, гомуми белем бирү учреждениеләрендә администрация, педагогик хезмәткәрләр, медицина хезмәткәрләре, укучылар коллективтан укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы зат һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссияләр төзелә, учреждение директоры боерыгы белән кадрлар ротациясе принцибын үтәп төзелә. Приказның күчермәсе ашханә администрациясенә тапшырыла. Укучыларның туклануын оештыруны контрольдә тоту буенча иҗтимагый комиссия әледән-әле (кварталга кимендә 1 тапкыр) учреждение җитәкчесе һәм инструктив-методик, педагогик киңәшмәләрдә әлеге йөкләмәләрне тикшереп тору һәм үтәү эше турында хисап тота.

2.6. Азык әзерләү технологиясен тикшерү көн саен җитештерү мөдире, медицина хезмәткәре, туклануны оештыру өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла, бу хакта бракераж (әзер ризыкны бәяләү) журналында билге ясала.

2.7. Туклану өчен түләү банклар аша муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының шәхси счетларына бирелә.

2.8. Белем бирү учреждениесе хезмәткәрләре арасыннан җитәкче боерыгы белән туклануны оештыру өчен җаваплы вазыйфаи зат билгеләнә.

2.9. Гомуми белем бирү учреждениесендә укучыларны ашату уку көннәрендә гамәлгә ашырыла. Азык кабул итү режимы белем бирү учреждениесе директоры тарафыннан раслана һәм танышу өчен уңайлы урынга урнаштырыла.

2.10. Һәр сыйныф укучылары өчен туклану алдан (1 көн эчендә) сыйныф җитәкчесе тарафыннан игълан ителгән укучылар саны нигезендә бирелә. Заявка төзегәндә, сыйныф җитәкчесе укучыларның санын исәпкә ала, ата-аналары (законлы вәкилләре) балалар дәрескә килә алмаган очракта алдан хәбәр итә.

2.11. Туклануны финанс ягыннан тәэмин итү түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла:

2.11.1 ата-ана акчалары;

2.11.2 муниципаль бюджет акчалары, шул исәптән уку елы дәвамында көн саен укучыларның туклану бәясе кыйммәтләнүен өлешчә компенсацияләү (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмнәрдә);

2.11.3 авыл мәктәпләренең мәктәп яны участогында яшелчә үстерүдән керемнәр.

## 3. УКУЧЫЛАРГА ТУКЛАНУ БИРҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә, укучыларның туклануы ирекле рәвештә башкарыла. Гаризада кайнар аш белән туклану һәм төрләре (иртәнге һәм (яисә) төшке аш) билгеләнә. Тулы, балансслы кайнар аш белән туклануны тәэмин итү көнгә бер балага туклану нормасыннан чыгып, үрнәк меню буенча дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашырырга вәкаләтле башкарма хакимият органының тиешле территориаль органы тарафыннан килештерелеп гамәлгә ашырыла. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклandыруны оештыруга карата Санитар-эпидемиологик таләпләр нигезендә (ата-аналар (законлы вәкилләр) акчалары исәбеннән), укучыларның иртәнге кайнар аш бәясе нормасы продуктларның расланган нормалары буенча исәпләнә.

3.2. Укучыларны кайнар аш белән туклandыру тәнәфесләрдә, 20 (дәвамлылыгында) минуттан да ким булмаган вакытта оештырыла. Һәр сыйныфка билгеле бер төшке аш өстәле беркетелә.

Укучылары туклandыру учреждение җитәкчесе раслаган график нигезендә башкарыла. Укучыларның туклануын сыйныф җитәкчесе контрольдә тота, иртәнге һәм төшке ашка килгән балалар санын исәпкә ала. Азык-төлек блогының эш режимы учреждениенең эш режимына туры килә һәм атнага 6 көн тәшкил итә.

3.3. Укучыларга кайнар ризык белән хезмәт күрсәтүне оештыру, өстәлләргә алдан 7-10 минут кала табын җәю (әзерләү) юлы белән башкарыла.

3.4. Ата-аналары (законлы вәкилләре) түләгән, әмма нигезле сәбәпләр аркасында бала туклана алмаган очракта, файдаланылмаган финанс акчалалары киләсе айга укучының туклану бәясеннән алына.

## 4. ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУ ПРОЦЕССЫНДА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫН БҮЛҮ

4.1. Укучыларны туклandыруны оештыру, шушы максатларга каралган бюджет акчаларын тоту, сәүдә-җитештерү эшчәнлеге, санитария-гигиена таләпләрен үтәү өчен җаваплылык белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, белем бирү оешмасына беркетелгән медицина хезмәткәренә, белем бирү оешмасы ашханәсенең җитештерү

мөдиренә һәм оешма җитәкчесенең боерыгы белән билгеләнгән затка йөкләнә.

4.2. Белем бирү учреждениесе җитәкчесе түбәндәгеләргә җаваплы:

–Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алабуга муниципаль районы норматив актлары, федераль санитария кагыйдәләре һәм нормалары, мәктәп уставы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә укучыларның туклануын оештыруга;

– әлеге Нигезләмәдә каралган локаль актлар кабул итүне тәэмин итүгә;

– белем бирү учреждениесе хезмәткәрләре арасыннан укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы булган затны билгеләргә;

– сыйныфта, гомуммәктәп ата-аналар җыелышында, шулай ук мәктәп идарәче советында укучыларны тукландыруны оештыру мәсьәләләрен карауны тәэмин итәргә.

4.3. Азык-төлек белән тәэмин итүче предприятие түбәндәгеләр өчен җаваплы:

- азык-төлек продуктларын вакытында тәэмин итүгә;

- китерелгән продукциянең сыйфатына;

- санитария кагыйдәләренең үтәлешенә һәм санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үтәүгә җитештерү контролен оештыруга;

- әлеге Нигезләмәдә һәм Учреждение белән төзелгән шартнамәдә каралган башка йөкләмәләрне үтәүгә.

4.4. Ел саен учреждение җитәкчесенең боерыгы белән билгеләнә торган җаваплы зат туклануны оештыру өчен түбәндәгеләргә бурычлы:

- әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда балаларга түләүсез туклану алу мөмкинлеге турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәгълүмат бирергә;

- бушлай кайнар аш белән тукланучы укучылар исемлекләрендәге үзгәрешләр турында мәгълүматны үз вакытында тапшырырга;

- тукланучылар санын төгәлләштерү өчен Учреждение укучыларын көн саен исәпкә алуны башкарырга;

- укучыларның туклануы буенча хисапны үз вакытында (1 числога кадәр ай саен) тапшырырга;

- стендта менюның булуын тикшерергә;

- әзерләнгән ризыкның менюга туры килүен тикшерергә;

- меню нормасының порция авырлыгын тикшерергә;

-сыйныф җитәкчеләренең эшчәнлеген координацияләүгә һәм контрольдә тотарга;

- укучыларның туклануына акча исәпләү өчен укучыларның исемлекләрен бухгалтериягә тапшырырга;

- укучыларның ашханәгә фактик йөрешен исәпкә алуны, барлык укучыларны туклану белән тәэмин итәргә, сыйныф буенча фактта алынган төшке ашларның күләмен исәпләү һәм түләү тәртибен контрольдә тотарга;

- туклану культурасын формалаштыруга буенча белем бирү учреждениесендә эшне координацияләүгә;

- мәктәп туклануының сыйфаты белән канәгать булу мониторингын тормышка ашырырга;

- туклануны оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертүгә.

4.5. Белем бирү учреждениесенең сыйныф җитәкчеләре түбәндәгеләргә җаваплы:

- ата-аналарга (законлы вәкилләргә) Учреждениядә туклануны оештыру турында мәгълүматны җиткерергә;

- тукланырга теләүче балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләрдән) гаризалар җыярга һәм учреждение администрациясенә тапшырырга;

- 48 сәгать эчендә уку көненә туклану оештыру өчен мәктәп ашханәсенә санлы заявка бирергә;

- тәкъдим ителгән заявканы көн саен иртәнге 8 сәгать 30 минуттан да соңга калмыйча ачыкларга;

- укучыларның көндезге ашын исәпкә алуының көндәлек табелен һәм ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) тукланууы өчен түләүне исәпкә алуны алып барырга;

- үз компетенцияләре өлешендә мәктәп тукланууын оештыруны мониторинглауны гамәлгә ашырырга;

- укучыларның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, балансллы һәм рациональ тукланууга ихтыяҗны формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар тәрбия эше планында каралган, даими рәвештә ата-аналар җыелышы барышында укучыларның яхшы сыйфатлы тукланууын тәэмин итү мәсьәләләре буенча фикер алышырга;

-учреждение җитәкчесе һәм педагогик киңәшмә утырышларында, азык-төлекне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә.

4.6. Укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) түбәндәгеләргә җаваплы:

- ай саен, 10 саннан да соңга калмыйча, баланың ашаганы өчен үз вакытында түләргә;

- сыйныф җитәкчесенә баланың авыруы турында яисә гомуми белем бирү учреждениесендә аның фактик яисә вакытлыча булмавы турында вакытында хәбәр итәргә, шулай ук медицина хезмәткәренә һәм сыйныф җитәкчесенә баланың кайбер ризыкларга аллергия реакцияләре булуы турында кисәтергә;

- сәламәт яшәү рәвеше һәм дөрес туклану күнекмәләрен тәрбияләү буенча үз балалары белән аңлату эшләре алып барырга;

- укучыларның туклануын оештыруны яхшырту буенча үз тәкъдимнәрен кертергә;

- укучыларның туклануын оештыруга акча хисаплары, үрнәк һәм көндәлек меню белән танышырга.

4.7. Мәктәп ашханәсендә, күренә торган урында, бракераж (әзер ризыкны бәяләү- куелган таләпләргә җавап бирү дәрәҗәсен тикшерү) комиссиясе, җәмәгать комиссиясе составы, меню, ашханә буенча сыйныфларның кизү тору графигы, ашханә буенча кизү тору вакыты, туклану культурасы буенча материаллар стенды, фикерләр һәм тәкъдимнәр китабы элеп куела.